ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

03.12.2021 Казан ш. № 441-120/кс-2021

«Аммоний» акционерлык җәмгыяте өчен техник суга 2022-2026 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Аммоний» АҖ) өчен әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә техник суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» АҖ өчен, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, техник суга 2022-2026 елларга тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» АҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.12.2021 № 441-120/кс-2021
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» АҖ өчен техник суга
2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Техник су тарифы (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Менделеевск муниципаль районы | | |
| 1 | «Аммоний» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелә) | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 13,44 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 13,53 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 13,53 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 14,27 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 14,27 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 14,47 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 14,47 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 15,25 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 15,25 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 15,48 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.12.2021 № 441-120/кс-2021
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Аммоний» АЖ өчен техник суга 2022 елга – 2026 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | "Аммоний" АЖ | | | | | | |
| 1.1 | Техник су | 2022 | 40853,05 | X | X | - | 0,57 |
| | | 2023 | X | 1 | X | - | 0,57 |
| | | 2024 | X | 1 | X | - | 0,57 |
| | | 2025 | X | 1 | X | - | 0,57 |
| | | 2026 | X | 1 | X | - | 0,57 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге